| | | |
|---|---|---|
| **У П Р А В Л Е Н И Е З А Г С**<br>**КАБИНЕТА МИНИСТРОВ**<br>**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ**<br>**Г Х А Т И Д А Р Ә С Е** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан ш.

2014 ел, 22 апрель № 35

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына куелган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда гражданнар һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы һәм “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре биләгәндә үз чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-329 номерлы Татарстан Республикасы Президенты указлары нигезендә **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына куелган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсендә (алга таба – Идарә) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген **(**алга таба – Исемлек) расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Югарыда күрсәтелгән Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфасын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфасы) биләгән гражданин, дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел дәвамында хезмәт килешүе шартларында оешмадагы вазыйфага куелу һәм (яки) әлеге оешмада ай дәвамында граждан-хокукый килешүе (граждан-хокукый килешүләре) шартларында йөз мең сумнан артык бәяләнүче эшләрне башкарырга (әлеге оешмага хезмәтләр күрсәтергә) хокуклы, әгәр әлеге оешманың дәүләт, (административ) идарә итүнең аерым функцияләре дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәттәге) бурычларына кергән булса һәм Идарәдәге дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибен һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләүгә карата таләпләрнең үтәлеше буенча тиешле комиссиянең ризалыгы булса.

2.2. Исемлеккә кертелгән Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел эчендә әлеге пунктның 2.1 пунктчасында күрсәтелгән эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турындагы граждан-хокук шартнамәләрен имзалаганда эш бирүчегә үзенең соңгы хезмәт итү урыны турындагы белешмәләрне хәбәр итәргә тиеш.

2.3. Исемлеккә кертелгән Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соң әлеге пунктның 2.2 пунктчасында каралган таләпне үтәмәве әлеге гражданин белән төзелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокукый килешүенең таркалуына китерә.

3. Хокукый, оештыру һәм кадр эше бүлеге түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

3.1. Әлеге боерык белән Исемлеккә кертелгән Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләрен таныштырырга тиеш.

3.2. Расланганнан соң Исемлекне Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә өч көн эчендә тапшырырга, ә соңыннан аларга, үзгәрешләр керткән очракларда, төгәлләштерелгән Исемлекне үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә тапшырырга тиеш.

4. 02.02.2010 ел, 6 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда һәм вазыйфасына куелган

гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында”,

25.08.2010 ел № 36 номерлы “02.02.2010 ел, 6 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда һәм вазыйфасына куелган гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсе боерыгына үзгәртүләр кертү турында”,

01.02.2011 ел № 5 “02.02.2010 ел, 6 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда һәм вазыйфасына куелган гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” (25.08.2010 ел № 36 номерлы боерык белән кертелгән үзгәртүләр белән) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсе боерыгына үзгәртүләр кертү турында”,

02.04.2013 ел № 55 “02.02.2010 ел, 6 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда һәм вазыйфасына куелган гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” (25.08.2010 ел № 36, 01.02.2011 ел № 5 номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәртүләр белән) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсе боерыгына үзгәртүләр кертү турында” боерыкларны үз көчен югалткан дип табарга.

5. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Идарә башлыгы** **Э.Ә.Зарипова**

ТР МК ЗАГС Идарәсенең
2014 елның 22 апрель
35 номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда гражданнар үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына куелган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы урынбасары.
2. Хокукый, оештыру һәм кадр эше бүлеге башлыгы.
3. Документларны формалаштыру, исәпкә алу, саклау һәм бирү бүлеге башлыгы.
4. Бухгалтер исәпләү һәм эшчәнлекне тәэмин итү секторы мөдире.
5. Хокукый, оештыру һәм кадр эше бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе.
6. Документларны формалаштыру, исәпкә алу, саклау һәм бирү бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе.
7. Мәгълүмати ресурслар секторы әйдәп баручы киңәшчесе.
8. Хокукый, оештыру һәм кадр эше бүлеге әйдәп баручы консультант.
9. Тикшерү һәм методик эшләр секторы әйдәп баручы консультант.
10. Бухгалтер исәпләү һәм эшчәнлекне тәэмин итү секторы әйдәп баручы белгеч.
11. Документларны формалаштыру, исәпкә алу, саклау һәм бирү бүлеге 1 разрядлы белгеч.